**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур., 29 нчы йорт.
Тел.3-44-56

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29,
Тел. 3-44-56

**КАРАР** — **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«01» ноябрь 2019 ел — № 2

**Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегенең Иске Кормаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Иске Кормаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Иске Кормаш авыл җирлеге Башлыгы **карар бирә:**

1. 2019 елның 14 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Шабизбаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2.. 2019 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Кыр-Каентүбә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

3. 2019 елның 15 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Яңа Балтач торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

4. 2019 елның 15 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

5. 2019 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә..

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

- торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;
- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру;
- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;
- ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;
- зират коймасын ремонтлау;
- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (грейдерлау,кардан чистарту);
- янгын гидрантларын,янгын краннарын урнаштыру ;
- янгын җиһәзләрен сатып алу;
- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр

- җирлек торак пунктында Игъланнар тактасы ясау һәм аларны урнаштыру;
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту.

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

7. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә:

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Шабизбаш авылы, Үзәк урамы, 21 нче йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Кыр-Каентүбә авылы, Үзәк урамы, 38 нче йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Яңа Балтач авылы, Үзәк урамы, 2 нче йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Балтач авылы, Үзәк урамы, 29 нчы йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Кормаш авылы, Үзәк урамы, 26 нчы йорт.

8. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

9. Әлеге карарны Иске Кормаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

10. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Ә Кашбразиев